Ифтар cvзе Уразада авыз ачуны, Рамазан аенда авыз ачу вакытында махсус чакырылган кунаклар мәжлесе. ИФТАР ИТҮ (КЫЛУ) – Ураза тоткан конне, кояш баегач, авыз ачу дигәнне анлата, дип язылган cvзлектә.

Жиһанда боек ай, айларнын солтаны булган Рамазан ае хәкимлек итә. Бу айда Мордовия авылларында, шул исәптән Саранск шәһәре мәчетләрендә дә, бергәләп авыз ачулар бик еш vтә башлады. Әле генә Кадошкино районы Иса авылы кешеләре авыл мәчетендә һәм Наиль белән Камиль Мангутовлар аерым оештырган изге ифтар мәжлесләре – авыз ачулар vткәрделәр. Знче июльдә Дубенка районы Ломат авылында да зурлап авыз ачканнар. Зурлап диюем шуннан, Дубенка районы Главасы Сергей Геннадьевич Плешаков (әлегә кадәр бирегә мондый бәйрәмгә район житәкчеләре килгәне булмаган), Ломат авылы житәкчесе Лариса Вячеславовна Киселёва бу кичәдә катнашканнар. Тирә-як районнардан, авыллардан да халык ифтарга кvпләп килгәннәр.

Район житәкчесе Сергей Геннадьевич барлык моселманнар очен кадерле булган кич

ә белән котлаган, исәнлек-саулык, иминлек теләгән vзенен нотыгында.

Раиль хазрәт әйтvенчә, Сергей Геннадьевич Дубенка районы газетасы аша да изге ай һәм изге бәйрәм белән котлады. Киләчәктә бер-беребезгә ярдәмләшеп, бер-беребезне анлап, хормәт итеп эшләргә кинәшләштек, ди.
Раиль хазрәт район житәкчесе С.Г.Плешаковка Коръән (рус телендәге тәржәмәсе) бvләк иткән.
Кичәне оештыручылар – авыл халкы, Ломат авылы предпринимательләре – Баймашевлар, Раимовлар һәм ин беренче чиратта - авыл мулласы Раиль хазрәт Мусин. «Бvгенге мәжлес кардәшлек, туганлык, авылдаш араларын тагын да якынайтты», - диде ул. Ломатта узган Рамазан аеннан бу Рамазан ае арасында эшләнгән эшләргә нәтижә ясап, ирешкән унышлар белән барлык кунакларны таныштырып узган.
Быел безнен жирлектә яшәvчеләргә уразаны 20 сәгатьләп тотарга туры килә. Хәдисләрдән мәгълvм булганча, фәрештәләр ураза тотучыларнын гонаһларын кичерvне сорап догалар кыла. Алла боерса, безнен ураза тотучы моселманнарга догалар кvбрәк тә ирешер, алар бит доньянын башка жирләрендә яшәvчеләргә караганда уразаны озаграк тота. Монда да Раббыбызнын бер хикмәте бар. «Ә инде бvгенге ифтар мәжлесен оештырып якташлык һәм туганлык араларын якынайтып олы vрнәк кvрсәттеләр», - диде Ломат авылында имам булып торган Раиль хазрәт. Коръән сvрәләре укып барча якыннар, әти-әниләр, авылдашлар рухына дога кылганнар, ди. Авыз ачып, ахшам намазын укыганнан сон мул табын артында Аллаһнын ризалыгын омет итеп, тәмледән-тәмле ризыклар белән сыйланганнар. Соныннан тәравих намазлары укып, барча ифтар мәжлесен оештырган кешеләргә рәхмәтләр әйтеп таралышканнар. Әйтеп китми булдыра алмыйм, чонки изге айда изге эшләр эшлиләр Ломат авылында: мәчеткә жыелган фитыр акчаларына, Раиль хазрәт житәкчелегендә, ашамлыклар сатып алып ярдәмгә мохтажларга таратканнар.

Наилә Насырова